

Мордовиядә билгесез кеше, машинаны сату турында башка кешенен белдерvен кулланып, Иссада яшәгән ирнен 300 мен сумга якын акчасын урлый.
Россия Эчке эшләр министрлыгынын Ләмберә тикшерv бvлегенә 28 яшьлек Исса кешесенә карата, кылынган алдау факты буенча, жинаять эше ачылган.
Алдан тикшерv барышында ачыкланганча, март ахырында Ромоданово районында яшәvче кеше бушлай белдерvләр сайтында «Лада Гранта» автомобилен сату турында хәбәр куйган.    Берникадәр вакыт узгач, ана билгесез кеше шалтыраткан һәм машина сатып алырга әзер булуын әйткән. Әнгәмәдәше ана ПТС фотосын жибәрергә һәм башка сатып алучылар аны бvтән борчымасын очен сату турында белдерvне алып ташларга кушкан.
Сонрак ачыкланганча, жинаятьче, кулында машина очен документлар тотып, vз исеменнән «Лада»ны сату турында мәгълvмат урнаштыра, шәхси телефон номерын кvрсәтә. Нәтижәдә, Пенза олкәсендә яшәvче кеше бу игълан белән кызыксына. Сойләшкәндә, аферист машинаны ана танышы кvрсәтәчәген һәм әгәр дә аны барысы да ошаса, сатып алучы акчаны vзе кvрсәткән счетка кvчерергә тиешлеген анлаткан. Шуннан сон ул чын сатучы белән элемтәгә керә һәм автомобиль алырга анын иптәше киләчәген, шуннан сон ана 297 мен сум кvчерәчәген хәбәр итә. Билгеләнгән вакытта сатып алучы Мордовиягә килә. Машинаны карап чыккач, зыян кvрvче банкоматка юл тота, анда ул жинаятьченен счетына акча кvчерә. Финанс операциясеннән сон ир-атлар алдау корбаннары булганнарын анлаган: нәтижәдә зыян кvрvче полициягә морәжәгать иткән.
Хәзерге вакытта алар тарафыннан булган хәлне билгеләvгә һәм жинаять кылуда катнашы булган кешеләрне эзләvгә юнәлдерелгән чаралар комплексы vткәрелә.
Кисәтv: таныш булмаган кешеләргә телефон аша хәтта “әйе” һәм “раслыйм” (подтверждаю) сvзләрен әйтv куркыныч, дип сойләгән РИА Новостига Дәvләт Думасы депутаты Антон Немкин. Мошенниклар финанс операцияләрен раслау яки килешvләр тозv очен тавышыгызны яздырып алырга момкин. Немкин сvзләренчә, тавыш аудиоязмасын кулланып алдау белән бәйле куркынычларны киметергә момкин. Монын очен банктагы исәп-хисап счеты белән операцияләр буенча смс-хәбәр итvне тоташтырырга кирәк. “Ниндидер шик булган очракта сез банк белән тиз арада элемтәгә керә аласыз һәм янаган куркыныч турында хәбәр итә аласыз” - дип анлаткан депутат.